ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№ 1 2024 елның 26 ноябрендәге

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Килди авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең Килди торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Килди торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны, 50% - Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар, 1 төркем инвалидлар, студентлар, күп балалы гаиләләр, 100% - мобилизацияләнгән гражданнар һәм контрактчылардан тыш,500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Килди торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Килди авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы В. М. Бурдин